ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.11.2020 п.г.т.Алексеевское № 432

**2020 елның IV кварталына гомуми торак мәйданының бер квадрат метрының уртача бәясен раслау турында**

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «2020 елның IV кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» 2020 елның 29 сентябрендәге 557/пр номерлы боерыгы нигезендә

**карар бирәм**:

1. 2020 елның IV кварталына Алексеевск муниципаль районы территориясендә «2020 - 2025 елларга Алексеевск муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру кысаларында гражданнарның торак шартларын яхшырту чараларын үткәрүгә социаль түләүләрне исәпләү өчен гомуми торак мәйданының бер квадрат метрының бәясен 53 919 сум 00 тиен күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары М.Р. Гайсинга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.А. Гайнуллин**